Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 4**

Балыклы-Чүкәй авылы 2025 елның 24 декабре

**2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджеты турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсендәге 10 өлешнең 2 пункты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 12 һәм 14-15 маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 маддәсендәге 8 өлешнең 2 пункты, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Уставының 19 маддәсендәге 2 өлешнең 3 пункты һәм 70,71 маддәләре нигезендә ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРӘ**:

**1 маддә**.

1. 2025 елга ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджетының төп сыйфатламаларын түбәндәгечә расларга:

1) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 5506,8 мең сум итеп;

2) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 5506,8 мең сум итеп;

3) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 0,0 мең сум итеп.

2. 2027 елга һәм 2028 елга ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджетының төп сыйфатламаларын түбәндәгечә расларга:

1) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2027 елга 5965,8 мең сум, 2028 елга 6477,4 мең сум итеп;

2) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2027 елга 5965,8 мең сум итеп, шул исәптән 149,1 мең сум күләмендә шартлы расланган чыгымнар, 2028 елга 6477,4 мең сум итеп, шул исәптән 323,9 мең сум күләмендә шартлы расланган чыгымнар;

3) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 2025 елга 0,0 мең сум, 2026 елга 0,0 мең сум итеп.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 маддә.**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча 2027 елның 1 гыйнварына булган торыш буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча 2028 елның 1 гыйнварына булган торыш буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча 2029 елның 1 гыйнварына булган торыш буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

**3 маддә.**

1. ТР Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджетында 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына фаразлана торган керемнәр күләмен 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 маддә.**

1. 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан маддәләре һәм чыгымнары төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджетының 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасын 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 маддә.**

1. Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә алына торган дотацияләр күләмен 2026 елга 2983,5 мең сум күләмендә, 2027 елга 3410,2 мең сум күләмендә, 2028 елга 3847,0 мең сум күләмендә расларга.

**6 маддә.**

1. Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренче хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тормышка ашыруга җирлекләр бюджетларына алына торган субвенцияләр күләмен 2026 елга 221,4 мең сум, 2027 елга 247,2 мең сум күләмендә, 2028 елга 315,2 мең сум күләмендә расларга.

**7 маддә.**

1. ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Шәмәрбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына 2026 елда һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә киңәш итәргә .

**8 маддә.**

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Балык Бистәсе районы территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

**9 маддә.**

1. Товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар буенча түләү өчен бирелгән 2026 елның 1 гыйнварына калган акчалары, әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә 2025 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмаган күләмдә 2026 елда, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиңдәшле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

**10 маддә.**

**1.** Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**11 маддә.**

1. Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балыклы-Чүкәй авылы, Мәктәп урамы, 30 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Башлыгы                    И.С.Мазитов